**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 11 июнендәге 2457 номерлы карары**

**«Академик Арбузов урамыннан алып проектлаштырыла торган 57 номерлы юлга кадәрге кишәрлектә автомобиль юлы төзелешенең беренче чираты» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын раслау турында**

Территорияләрне шәһәр төзелеше документлары тәэмин итү максатыннан, «Беренчел документацияне әзерләү үзәге» муниципаль унитар предприятиесе тәкъдиме нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 43, 45 һәм 46 статьяларына таянып, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 2 апрелендәге 575 номерлы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 17 гыйнварындагы 14 номерлы карарлары нигезендә, 2023 елның 13 октябрендәге ЦПИД-исх/372 номерлы гариза кысаларында үзгәрешләр кертү проектын эшләү эшенең 2023 елда башланып китүен исәпкә алып, **карар бирәм**:

1. «Академик Арбузов урамыннан алып проектлаштырыла торган 57 номерлы юлга кадәрге кишәрлектә автомобиль юлы төзелешенең беренче чираты» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, сервитут билгеләү тәкъдим ителә торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән кала (хезмәттә файдалана торган материаллар), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

3. Билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, сервитут билгеләү тәкъдим ителә торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән кала (хезмәттә файдалана торган материаллар), әлеге карарны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 11 июнендәге
2457 номерлы карары белән
расланды

**«Академик Арбузов урамыннан алып проектлаштырыла торган 57 номерлы юлга кадәрге кишәрлектә автомобиль юлы төзелешенең беренче чираты» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проекты**

«Академик Арбузов урамыннан алып проектлаштырыла торган 57 номерлы юлга кадәрге кишәрлектә автомобиль юлы төзелешенең беренче чираты» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проекты түбәндәгеләрдән тора:

I. Территорияне планлаштыру проекты. График өлеш. Кызыл линияләр сызымы. Линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре сызымы. Урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре сызымы

II. Линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән линия объектын урнаштыру турында нигезләмә.

III. Территорияне ызанлау проекты. График өлеш. Территорияне ызанлау сызымы.

IV. Территорияне ызанлау проекты. Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, планлаштырыла торган сервитутның характерлы нокталары координаталары исемлеге белән текстлы өлеш.

Билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге, линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары

координаталары исемлеге, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, планлаштырыла торган сервитут чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге хезмәт урынында файдалана торган документлар булып тора һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (wdocskskn.ru) бастырып чыгарылырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

# I. Территорияне планлаштыру проекты. График өлеш. Кызыл линияләр сызымы. Линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре сызымы. Урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре сызымы



## II.Линия объектын урнаштыру турында нигезләмә

Территорияне планлаштыру проекты Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьялары нигезендә 2021 елның 16 гыйнварындагы 17/Р номерлы линия корылмасы территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын эшләү килешүе буенча әзерләнгән.

Проектлана торган автомобиль юлы Казанның Совет районында урнашкан, 1 нче Владимир урамыннан алып Каспий урамына кадәр уза.

Территорияне планлаштыру проекты «Академик Арбузов урамыннан алып проектлаштырыла торган 57 номерлы юлга кадәрге кишәрлектә автомобиль юлы төзелешенең беренче чираты» автомобиль юлының бер өлеше өчен әзерләнде, 1 этапта 1 нче Владимир урамыннан Каспий урамына кадәр автомобиль юлын төзү каралган. Шул сәбәпле проектта линия объектын урнаштыру зонасы 1 этапта автомобиль юлы төзү участогына гына билгеләнгән.

Әлеге проектка кермәгән автомобиль юлы участокларына территорияне проектлауның алдагы этапларында территорияне планлаштыру буенча аерым документлар эшләнәчәк, аларда Академик Арбузов урамыннан алып проектлаштырыла торган 57 номерлы юлга кадәрге кишәрлектә автомобиль юлын реконструкцияләү һәм/яки ремонтлау, төзү каралачак.

Район уртача континенталь климат зонасында урнашкан һәм төзелеш өчен климат буенча районлаштыру схемасы картасы нигезендә IIВ ярдәмче районына керә, Россия Федерациясен районлаштыруның III юл-климат зонасына карый.

Территориянең климат характеристикасы 131.13330.2020 кагыйдәләр җыелмасы мәгълүматлары буенча, Казан шәһәре метеостанциясендә күпьеллык күзәтү материаллары буенча китерелгән. Территорияне җир асты һәм җир өсте инженерлык челтәрләре булу характерлый.

Территорияне планлаштыру проекты белән гомуми файдаланудагы территориянең чикләрен билгеләүче кызыл линияләр билгеләнә. Линия объектын план буенча урнаштыру чикләре билгеләнә торган кызыл линияләр чикләрендә төзелә торган автомобиль юлы кишәрлегенең урнашуын исәпкә алып кабул ителде.

Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының Генераль планы нигезендә (алга таба – Казан шәһәренең генераль планы) Академик Губкин урамында d-

600 магистраль суүткәргеч тоннель, d-315 суүткәргеч төзү, эшләп килүче d-1200 яңгыр канализациясен реконструкцияләү каралган. Билгеләнә торган кызыл линияләр линия объектын һәм перспектив инженерлык коммуникацияләрен урнаштыру өчен техник коридорны исәпкә алып проектлаштырылган.

Казан шәһәренең генераль планы нигезендә «Академик Арбузов урамыннан алып проектлаштырыла торган 57 номерлы юлга кадәрге кишәрлектә автомобиль юлы төзелешенең беренче чираты» линия объекты «Көйләнә торган хәрәкәтле гомумшәһәр әһәмиятендәге магистраль урам» категориясенә карый.

Территорияне планлаштыру проектының чик мәйданы 4331 кв.м тәшкил итә. Линия объектын план буенча урнаштыру зонасының чик мәйданы – 3085 кв.м.

Юлның техник характеристикалары һәм параметрлары 42.13330.2016 кагыйдәләр җыелмасы буенча кабул ителде һәм 1 нче таблицада бирелде.

1 нче таблица

**Юлның техник характеристикалары һәм параметрлары**

| № т/б | Аталышы | Изм-ль | Күрсәткеч |
|---|---|---|---|
| 1 | Төзелеш төре | | Яңа төзелеш |
| 2 | Юл категориясе | | Җирле әһәмияттәге урамнар һәм юллар: торак төзелеше зоналарындагы урамнар |
| 3 | Исәпләнгән тизлек | км/сәг | 40 |
| 4 | Юл катламнары тибы һәм өслекнең төре | | Капиталь, асфальт-бетон |
| 5 | Хәрәкәт полосалары саны | данә | 2-3 |
| 6 | Хәрәкәт полосасы киңлеге | м | 3,5 |
| 7 | Машина юлының киңлеге | м | 7-13,2 |
| 8 | Кырыйдагы куркынычсызлык полосасы киңлеге | м | - |
| 9 | Пландагы кәкренең иң кечкенә радиусы | м | 40 |
| 10 | Күчәр буйлап иң зур авышлык | ‰ | 72 |
| 11 | Күчәр буйлап иң кечкенә авышлык | ‰ | 5 |
| 12 | Буй профильдә кәкренең иң кечкенә радиусы: | | |
| | - кабарынкы кәкренең | м | 4600 |
| | - батынкы кәкренең | м | 650 |
| 13 | Исәп-хисап йөкләнешләре: | кН | 115 |
| | - юл киеменә | | |
| 14 | Тротуар киңлеге | м | 1,5-2,25 |

Линия объектын план буенча урнаштыру зоналарының чикләре гамәлдәге җир кишәрлекләрен исәпкә алып билгеләнде.

Линия объектларын урнаштыру зоналары гамәлдәге нормативлар нигезендә билгеләнде. Әлеге объектларны башкача урнаштыру мөмкин түгел (территорияне планлаштыру проектына ЧРЗ/258/2023 номерлы фәнни-тикшеренү хисабы кушымта итеп бирелә).

Линия объектларын урнаштыру зоналары чикләренә туры килә торган, урнаштыру әлеге кишәрлекләрне алардан рөхсәт ителгән файдалану төре буенча куллану мөмкин булмауга китерәчәк яисә алардан файдалануда җитди кыенлыкларга китерәчәк җир кишәрлекләре һәм аларда урнашкан капиталь төзелеш объектлары муниципаль ихтыяҗлар өчен мәҗбүри алынырга тиеш.

Дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен резервлау һәм (яисә) мәҗбүри алу күздә тотыла торган җир кишәрлекләре исемлеге, аларның адресы яки урнашкан урыны тасвирламасы 2 нче таблицада бирелгән.

2 нче таблица

**Дәүләт ихтыяҗлары яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен резервлау һәм (яки) мәҗбүри алу күздә тотыла торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары, аларның адреслары яки урнашкан урыны тасвирламасы**

| Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Адресы | Резервлау/ алу |
|---|---|---|
| 16:50:140208:6 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Совет районы, 1 нче Владимир ур., 34 йорт | Өлешчә |
| 16:50:140208:84 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Совет районы, Академик Губкин ур., 126 йорт | Тулысынча |
| 16:50:140208:33 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Совет районы, Академик Губкин ур., 128 йорт | Тулысынча |
| 16:50:140205:6 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Совет районы, Академик Губкин ур., 87 йорт | Өлешчә |

Өлешчә һәм тулысынча резервланырга һәм (яисә) мәҗбүри алынырга тиешле җир кишәрлекләренең мәйданнары һәм чикләре территорияне ызанлау проекты материалларында китерелгән.

Җирләрне бүлеп бирү күләмнәре проектлауның гамәлдәге нормаларын һәм кагыйдәләрен, төзелешне оештыру буенча карарларны исәпкә алып, җирләрне минималь мәҗбүри алу, технологик максатчанлык шартларыннан чыгып кабул ителә.

Объектларны төзү, эксплуатацияләү һәм төзекләндерү өчен махсус бүленгән җир полосасы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 2 сентябрендәге 717 номерлы «Автомобиль юлларын һәм (яки) юл сервисы объектларын урнаштыру өчен җирләрне бүлеп бирү нормалары турында»гы карары нигезендә кабул ителде.

## Инженерлык инфраструктурасы объектларының характеристикасы

**Тышкы яктырту**

Тышкы яктырту челтәрләрен төзү проектлаштырылган.

Казан электр челтәрләренең гамәлдәге трансформаторлы ярдәмче станциясе тәэмин итү чыганагы булып тора.

Тәэмин итә һәм бүлә торган челтәрләрне җирдәге бронялы кабельдән ясау каралган. Тышкы яктырту кабельле челтәрләре эшләп килүче һәм проектлана торган автомагистральләр белән кисешкән урыннарда резерв гильзасы каралган.

**Яңгыр канализациясе**

Әлеге бүлектә Академик Губкин урамындагы, Җиңү проспектыннан алып Нокса елгасына кадәрге кишәрлектә, яңгыр сулары коелары һәм күзәтү коелары ясап, чыгару урынын ясап, яңгыр канализациясе коллекторын күчереп салу проектлаштырылган.

Саклануны тәэмин итү максатыннан, бикләү механизмнары белән җиһазландырылган яңгыр канализациясе люкларын һәм рәшәткәләрен урнаштыру каралган.

**Юл хәрәкәте белән идарә итүнең автоматлаштырылган системасы.**

Хәрәкәт куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм машина йөртүчеләрнең һәм җәяүлеләрнең хәрәкәтен оештыру өчен проектта КВВГНГ контроль кабелен, шулай ук светофор терәкләрен төзелеш зонасыннан читкә чыгару каралган.

Шулай ук юл билгеләре кую, юл киртәләре кую, юл тамгалары ясау каралган.

Б тибындагы яктылык кайтара торган өслекле юл билгеләрен урныштыру «Юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары» ГОСТ Р 52289-

2019 нигезендә каралган. Юл билгеләрен, тамгаларын, светофорларны, юл коймаларын һәм юнәлдерүче җайланмаларны куллану кагыйдәләре». Юл билгеләренең терәк баганалары һәм баганалар өчен фундаментлар 3.503.9-80 И-7-88 «Автомобиль юлларында юл билгеләре баганалары» сериясе проекты буенча проектланган.

**Су белән тәэмин итү**

Проектта, юл төзелеше зонасына эләгә торган барлык коеларны саклап калып, су белән тәэмин итү челтәрләрен саклап калу һәм яңадан салу каралган.

**Электр белән тәэмин итү**

Проектта юл төзелеше зонасына эләгә торган эшләп килүче электр линияләрен реконструкцияләү каралган.

**Элемтә челтәрләре**

Проектта, баланс тотучыларның техник шартлары нигезендә, элемтә линияләрен саклау һәм яңадан салу каралган.

**Газ белән тәэмин итү**

Техник шартларга ярашлы рәвештә проектта җир асты газүткәргечендә саклау футлярлары урнаштыру һәм җир өсте газүткәргечен яңадан салу каралган.

## Линия объектын урнаштыруга бәйле рәвештә мәдәни мирас объектларын мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклау чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат

Территорияне планлаштыру проекты чикләрендә «Казан Алла Анасы чиркәве» мәдәни мирас объектын саклау зонасы урнашкан (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 20 августындагы 715 номерлы карары).

1. Әлеге зонада рөхсәт ителә:

1.1. Мәдәни мирас объектын саклауга һәм популярлаштыруга юнәлдерелгән, шул исәптән объектны тарихи-шәһәр төзелеше һәм табигый мохитендә сакланышын тәэмин итә торган эшләр башкару.

1.2. Капиталь төзелеш объектларыннан һәм җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре, Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә файдалану.

1.3. Гамәлдәге капиталь төзелеш объектларын аларның параметрларын (биеклеген һәм төзелеш мәйданын) арттырмыйча капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү.

1.4. Фасадлар бизәлешендә: материаллар – агач; кирпеч һәм буяу өчен

фасад штукатуркаларын; буяулар – мәдәни мирас объектының төсенә туры килә торган төсләр гаммасын куллану.

1.5. Төбәк әһәмиятендәге «Казан шәһәре» тарихи җирлеген саклау предметын тәшкил итүче тарихи кыйммәткә ия шәһәр формалаштыручы объектларга кертелмәгән капиталь төзелеш объектларын сүтү (демонтажлау).

1.6. Нокса елгасы аша булган күперне капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү, кирәк булганда яңасын төзү.

1.7. Гамәлдәге инженерлык инфраструктурасын капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү, яңа инженерлык челтәрләрен җир асты юлы белән салу, кирәк булганда, яңа инженерлык объектларын (трансформатор пункты, газ көйләү пункты һ.б.) урнаштыру.

1.8. Биналарда һәм корылмаларда, бинаның икенче катындагы тәрәзә уемнарының аскы кырыеннан биек булмаган урында күләмле хәрефләр һәм билгеләр рәвешендә урнаштырып, биеклеге 0,5 метрдан артык булмаган һәм озынлыгы бер метрдан артмаган консоль корылмаларны урнаштырып, тышкы мәгълүмат чаралары урнаштыру.

1.9. Мәдәни мирас объекты территориясе белән чиктәш җир кишәрлекләрендә, барлык төр эшләрне мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү бүлеге булганда башкару.

1.10. Территорияне төзекләндерү, аңа түбәндәгеләр керә:

- яшелләндерү эшләрен башкару: газоннар, чәчәк түтәлләре ясау, булган агачларны һәм куакларны саклау, санитар кисүләрдән тыш, яңаларын утырту;

- яңгыр һәм кар суларын агызу системасын оештырып, җәяүле өлештә тротуар плитәсен кулланып, юлларга, мәйданнарга капиталь ремонт ясау;

- юлның җәяүлеләр һәм машиналар йөри торган өлешләрен бүлә торган чик буйлап 1,2 метрдан да артык булмаган биеклектәге үтә күренмәле койма урнаштыру;

- махсус билгеләнгән мәйданчыкларда парковкалар оештыру;

- барлыкка килгән төзелешнең тышкы архитектур күренешенә туры килә торган төзекләндерү элементларын урнаштыру.

2. Тыела:

2.1. Мәдәни мирас объектының тарихи-шәһәр төзелеше мохитен саклап калуга һәм торгызуга (регенерацияләүгә) юнәлтелгән махсус чараларны кулланудан тыш (тарихи-шәһәр төзелеше мохитен, өлешчә яки тулысынча югалкан элементларны һәм (яки) характеристикаларны торгызу, тулыландыру, шулай ук линия объектлары салу), капиталь төзелеш объектларын төзү.

2.2. Мәдәни мирас объектына һәм әйләнә-тирә төзелешкә тискәре

йогынты ясый торган төзелеш технологияләрен куллану.

2.3. Ут кабу куркынычы булган материаллар урнаштыру.

2.4. Фасадларны фрагментлап бизәү, бинаның тышкы архитектур күренешен боза торган материаллар һәм төс гаммаларын (кара төс һәм неон төсләр) куллану, шулай ук материаллардан файдалану һәм фасадларны буяу буенча югарыда күрсәтелгән таләпләрне үтәмәү.

2.5. Мәдәни мирас объекты территориясе чигеннән 100 метрдан кимрәк ераклыкта каты көнкүреш калдыклары җыю өчен контейнерлар урнаштыру.

2.6. Гомуми файдаланудагы территорияләрне (урамнарны, машина юлларын, мәйданны) формалаштыра торган биналарның фасадында кондиционерлар, антенналар һәм башка техник җиһазлар урнаштыру.

2.7. Конструкцияләре аларны саклау предметы булып торган, ягъни бина төзелешенең башлангыч проектында каралган, тарихи кыйммәткә ия шәһәр формалаштыручы объектларга кертелгән биналардан тыш, биналар һәм корылмаларның түбәләрендә төрле корылмалар (тышкы мәгълүмат чаралары) урнаштыру.

2.8. Тәрәзә һәм ишек уемнарын тулысынча яки өлешчә каплый торган тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру.

2.9. Реклама корылмаларының барлык төрләрен урнаштыру.

2.10. Булган төзелешнең тышкы архитектур йөзен боза торган тышкы мәгълүмат чараларын фасадларның архитектур үзенчәлекләрен исәпкә алмыйча урнаштыру, шул исәптән:

- театр, музей афишаларын, шулай ук витриналар урнаштыру өчен булган корылмалардан тыш, фон корылмалары, яктылык тартмалары рәвешендә;
- эре габаритлы корылмалар;
- җемелдек ут, яктыртуның ачык ысулын кулланып.

## Әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат

Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү нәтиҗәләре буенча автомобиль юлы төзелешенең тискәре йогынтысын кисәтү һәм киметү буенча табигатьне саклау чаралары комплексы эшләнде.

**Җир ресурсларын һәм туфрак катламын саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану чаралары**

Билгеләнгән эшчәнлекнең җирдән файдалану шартларына һәм территориянең туфрак катламына тискәре йогынтысын киметү өчен түбәндәге

чараларны алдан күрергә кирәк:

- машиналарның һәм механизмнарның эшләвен һәм хәрәкәтләнүен бары тик җирләр төзү өчен билгеләнгән чикләрдә генә оештырып, гамәлдәге юлларның технологик юллары өчен максималь кулланылып оештыру;

- алдан каралмаган урыннарда төзелеш материалларын төзүне һәм саклауны тыю;

- җитештерү һәм куллану калдыкларын саклау һәм утильләштерү урыннарына махсус контейнерларга җыю, аларны чыгару;

- төзелеш мәйданчыкларында барлыкка килә торган җитештерү һәм көнкүреш агынтыларын проектта каралган тәртиптә җыю һәм чыгару;

- туфрак катламын ягулык-майлау материаллары белән пычратуны булдырмау максатыннан махсус билгеләнгән урыннарда автотранспортны ягулык белән тәэмин итү;

- махсус билгеләнгән мәйданчыкларда машиналарга һәм механизмнарга техник хезмәт күрсәтү;

- бозылган җирләрне рекультивацияләү;

- төзелеш эшләре тәмамланганнан соң, өслекнең табигый рельефын саклап калып, җир бүленгән полосада ахыргы планлаштыру.

**Атмосфера һавасын саклау чаралары**

Объектны реконструкцияләү чорында атмосфера һавасын пычратуның төп чыганаклары булып йөк машиналары һәм юл техникасы двигательләре эше, эретеп ябыштыру эшләре, буяу һәм казу-төяү, гидроизоляцияләү эшләре, юл өслеген төзү эшләре тора. Барлык чыганаклар да – оештырылмаган.

Пректлана торган объектны төзегәндә янәшә территорияләр өчен атмосфера һавасына пычраткыч матдәләрнең тискәре йогынтысын киметү максатыннан түбәндәге чаралар каралган:

- төзелеш машиналарының һәм механизмнарның эше янган газларны рөхсәт ителгән минималь чыгару дәрәҗәсенә һәм тавыш дәрәҗәсенә көйләнгән булырга тиеш;

- төзелеш технологияләренә җәлеп ителмәгән техниканы теләсә кайсы вакытта эшләп тора торган двигательләр белән калдыруны тыю;

- бушка йөрүне булдырмау;

- бер үк вакытта эшли торган төзелеш техникасы санын мөмкин кадәр киметү;

- җитештерү технологияләрен катгый үтәү;

- эшкәртелгән газларның агуын һәм төтенен контрольдә тоту;

- двигательләрне җылыту һәм эшләтеп җибәрүне җиңеләйтә торган

җайланмалар куллану;

- хәрәкәттәге составның агуын һәм төтенен техник яктан тикшерү һәм контрольдә тоту срокларын катгый үтәү;

- билгеләнгән вакытта техник тикшерү уздыру, техник хезмәт күрсәтү, планлы-кисәтү ремонты хисабына юл һәм автотранспорт техникасын төзек хәлдә тоту;

- төзек булмаган яки көйләнмәгән двигательле һәм тиешле стандартларга туры килми торган ягулыклы техникадан файдалануны тыю;

- материаллар җыю-саклау зонасын өч яктан койма белән әйләндереп алу, түбәле корылма ясау;

- тузансыман материалларны (грунт, ком) су белән чылату, бу материалларның җил белән таралуын булдырмый;

- грунт бушату өчен билгеләнгән участокларны җилдән ышык яктан җиһазлау һәм урнаштыру;

- материаллар җыю-саклау зонасын өч яктан койма белән әйләндереп алу, түбәле корылма ясау;

- калдыкларның теләсә нинди төрен яндыруны тыю.

**Төзелеш чорында территориянең үсемлекләр һәм хайваннар дөньясына тискәре йогынтыны булдырмау яисә андый йогынтыны киметүгә юнәлдерелгән чаралар**

Эшләр башкарганда төзелеш участогында үсемлекләр капламы тулысынча юкка чыгарыла. Йогынты зонасында үсемлекләр механик яктан зыян күрәчәк яки эшли торган техниканың янган агулы газ калдыклары нәтиҗәсендә зарарланачак. Төзелеш эшләрен башкарганда табигатьне саклау буенча төп бурыч булып, алга таба эксплуатацияләгәндә техноген йогынтыны яки тәэсирне минимальләштерү тора.

Үсемлекләргә тискәре йогынтыны киметү максатыннан түбәндәге чараларны башкару кирәк:

- төзелеш эшләрен табигатьне саклау нормаларын үтәп, проект карарларына катгый туры китереп башкару;

- техниканы махсус билгеләнгән юллар буенча гына йөртү;

- төзелеш һәм көнкүреш чүп-чарын үз вакытында җыештыру, чүп-чар өемнәрен бетерү;

- вак урман эшләрен башкару кирәк булган очракта, янгыннар һәм корткычлар үрчү өчен уңай шартлар тудырмас өчен, киселгән материалларны яхшылап җыештыру;

- янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен төгәл үтәп, төзелеш

территориясендә һәм аның тирә-ягында янгын чыгу ихтималын бетерү;

- агач кәүсәләренә кадәр 2 м һәм куакларга кадәр 1 м ераклыкта җир эшләрен башкаруны, агач ябалдашына яисә кәүсәләренә кадәр 0,5 метрдан азрак ераклыкка йөкләр күчерүне, агач күәсәләре тирәли вакытлыча коймалар һәм саклагыч корылмалар урнаштырмыйча, алардан кимендә 2 м ераклыкта торбалар һәм башка материаллар өюне тыю;

- төзелеш мәйданчыкларында һәм янәшә территориядә үсемлекләр яндыруны, учак кабызуны, калдык һәм чүп-чар яндыруны тыю;

- проектта каралган рекультивация үткәрү.

**Су тирәлегенә йогынтыны киметү чаралары**

Җир өсте һәм җир асты су ресурсларына тискәре йогынтыны булдырмау өчен түбәндәге чараларны үтәүне күздә тотарга кирәк:

- булган юллардан тыш башка җирләрдән транспорт йөрүне тыю;

- машиналарны һәм механизмнарны бу максатлар өчен каралмаган урыннарда юуны һәм ремонтлауны булдырмау;

- ягулык-майлау материалларын махсус билгеләнгән урыннарга агызу, алга таба аларны утильләштерү һәм чистарту;

- төзелеш мәйданчыгында ягулык саклауны булдырмау;

- очраклы рәвештә яки авария булганда нефть продукциясе грунтка түгелгән очракта, түгелгән сыекчаны механик рәвештә җыю, пычранган грунтны зарарлы матдәләрне үзенә сеңдерә торган материал (торф, агач йомычкасы, пычкы чүбе, ком) белән бергә катнаштыру, алга таба катнашманы, җирле контроль органнары белән килештереп, калдыкларны күмү өчен махсус билгеләнгән урыннарга чыгару;

- өслек һәм кар суларының табигый агышын саклау;

- су объектына яки урын рельефына пычранган хуҗалык-көнкүреш суларын агызуны тыю. Хуҗалык-көнкүрештәге юынтык суларны биобәдрәфкә җыю һәм аларны шәһәр канализациясенең агызу станциясенә чыгару күздә тотыла;

- җитештерү һәм куллану калдыкларын җыю һәм үз вакытында утильләштерүне оештыру;

- вакытлы биналарны һәм корылмаларны сүтү, җирләрне рекультивацияләү;

- грунт, лак-буяу материаллары, битум, бензин һ.б. эләгүне булдырмау өчен вакытлыча складларны су объектының яр буе полосасыннан һәм су саклау зонасыннан читтә урнаштыру;

- яр буе полосасыннан һәм су объектларының су саклау зонасыннан читтә

көнкүреш, хуҗалык һәм ярдәмче биналар урнаштыру;

- җитештерү һәм көнкүреш суларын җир өсте һәм җир асты суларын пычрату мөмкинлеген булдырмый торган итеп җыюны һәм чыгаруны оештыру;

- эш урыннарын һәм вакытлы торакларны көнкүреш һәм төзелеш калдыклары өчен инвентарь контейнерлар белән тәэмин итү;

- су белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау зоналары режимын үтәү;

- өске һәм кар суларының табигый агышын саклау эшләре тәмамланганнан соң, төзелеш полосасын планлаштыру.

**Калдыкларның әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын киметүгә юнәлдерелгән чаралар**

Табигый мохитне (үсемлекләрне, туфракны, җир асты суларын һәм җир асты байлыкларын) төзелеш калдыклары белән пычранудан саклауны тәэмин итү буенча экологик таләпләрне үтәү өчен төзелеш һәм көнкүреш калдыклары белән эш итү системасын оештырырга кирәк. Система түбәндәгеләрне күздә тотарга тиеш:

табигатьне саклау законнары таләпләре нигезендә эшләр башкару участогында калдыкларны вакытлыча саклау шартларын үтәү;

төзелеш-монтаж эшләре вакытында барлыкка килә торган инертлы төзелеш материаллары калдыкларын аннан соңгы технологик операцияләрдә файдалану бу калдыкларның иң аз күләмен күмүне һәм табигать ресурсларын саклауны тәэмин итә;

алга таба эшкәртү предприятиесенә урнаштыру, шулай ук күмү полигонына чыгару өчен, барлыкка килә торган калдыкларны төрләре һәм класслары буенча аерым җыюны оештыру;

төзелеш эшләре башланыр алдыннан калдыкларны махсуслаштырылган оешмаларга тапшыру турында килешүләр төзү;

биобәдрәф калдыкларын чистарту корылмаларына чыгару;

калдыкларны рөхсәтсез урнаштыруны һәм территорияләрне чүпләүне булдырмас өчен аларны урнаштыру һәм эшкәртү урыннарына даими рәвештә ташу;

калдыкларны эшкәртү яисә күмү өчен башка объектларга тапшыруның шартларын үтәү;

калдыкларны илтүгә карата санитар-экологик таләпләрне үтәү.

**Тавыштан саклау чаралары**

Проектта төзелеш эшләрен башкарганда эшләр алып бару чорына тавыштан саклау буенча оештыру характерындагы түбәндәге чараларны күздә

тотарга тәкъдим ителә:

- төзелеш эшләрен минималь сандагы машина һәм механизмнар белән башкару;

- минималь шау-шу характеристикалары булган төзелеш техникасын куллану, иң шау-шулы характеристикалары булган, 5 берәмлектән дә артык булмаган техниканың бер үк вакытта эшләве. Төзелеш техникасының шау-шуын киметү һәм двигательләрнең тавыш изоляциясен арттыру өчен резинадан, поролоннан күп катлы өслекле саклагыч япма һәм капотлар кулланырга тәкъдим ителә;

- төзелеш мәйданчыгы буенча автомашиналар хәрәкәте тизлеген чикләү;

- төзелеш техникасын бүлеп урнаштыру.

- иң каты тавыш чыгаручы техниканың өзлексез (туктаусыз) эшләү вакытын чикләү (бер сәгать эчендә 10-15 минуттан артык түгел);

- төзелеш мәйданчыгы буенча машиналар хәрәкәтен чикләү;

- каты тавыш чыгара торган төзелеш механизмнарын торак, иҗтимагый һәм административ биналардан мөмкин кадәр ераграк урнаштыру;

- төзелеш вакытында гидравлика белән көйләнә торган үзгәрүчән эксцентриситет белән чыгарыла торган югары ешлыклы вибротөягечләр файдалану.

Эшләрне бер үк вакытта башкармау, төзелеш машиналарының һәм автотранспортның эш дәвамлылыгын кыскарту, кичке һәм төнге сәгатьләрдә эшне туктату, чит илдә җитештерелгән, ГОСТ таләпләренә туры килә торган заманча юл-төзелеш техникасын куллану, механизмнарны үз вакытында ремонтлау кебек эшләрне башкаруның рациональ технологиясен куллану юлы белән төзелеш мәйданчыгыннан чыккан тавыш дәрәҗәсен түбәнәйтүгә ирешергә мөмкин;

- мәҗбүри тик тору яки эшләгәндә техник тәнәфес вакытында техниканы двигатель эшләмәгән режимда гына калдыру рөхсәт ителә;

- төзелеш эшләрен төзелеш техникасының эш вакыты графигы буенча башкарырга; көндезге вакытта (23.00 дән 7.00 сәгатькә кадәр эшләүне тыю), ял һәм бәйрәм көннәрен исәпкә алып.

Төзелеш мәйданчыгы территориясе периметры буйлап торак төзелеше ягыннан территорияне каплап тора торган 2,2 м биеклектәге тоташ койма урнаштырылачак. Әлеге чара торак йортлар территориясенә шау-шу йогынтысын киметергә мөмкинлек бирәчәк.

**Территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, шул исәптән янгын куркынычсызлыгын һәм**

**гражданнар оборонасын тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат**

Проектлана торган корылмаларның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен проект буенча түбәндәгеләр каралган:

- технологик җиһазларны, шартлау куркынычы категориясен исәпкә алып, нормалар буенча кирәкле юлларны тәэмин итеп һәм кирәк булган янгынга каршы өзеклекләрне исәпкә алып урнаштыру;

- объектны файдалануга тапшыру алдыннан янгын куркынычсызлыгы өчен җаваплы кешеләр билгеләнә.

Пычраткыч матдәләрнең җир өсте һәм җир асты суларына йогынтысын булдырмау һәм аның нәтиҗәләрен киметү өчен төзелеш вакытында ягулык-майлау материаллары түгелүне булдырмау мөһим.

Төзелеш эшләре алып бару этабында атмосфера һавасын саклау буенча төп чара – сертификацияләнгән ягулык һәм майлау материаллары куллану.

Техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр шартлаулар, янгыннар, һәлакәтләр, химик һәм радиоактив матдәләр чыгару, техносфера объектларында җимерелүләр, төшү-авулар, ишелүләр нәтиҗәсендә барлыкка килә.

Проектлана торган линия объекты территориясенә иң якын янгыннан саклау бүлекчәсе булып Россия Федерациясе Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе тора, ул түбәндәге адрес буенча урнашкан: 420088, Казан шәһәре, Академик Губкин урамы, 50.

**Гражданнар оборонасы буенча чаралар**

Линия объектының карап тикшерелә торган территориясе мөмкин булган җимерелүләр, химик һәм радиоактив зарарлану, һәлакәтле су басу зоналарына эләкми. Гражданнар оборонасы буенча махсус чаралар әзерләү һәм үткәрү таләп ителми.

# III. Территорияне ызанлау проекты. График өлеш.
# Территорияне ызанлау сызымы (1 нче этап)



## III. Территорияне ызанлау проекты. График өлеш.
## Территорияне ызанлау сызымы (2 нче этап)



## IV. Территорияне ызанлау проекты

«Академик Арбузов урамыннан алып проектлаштырыла торган 57 номерлы юлга кадәрге кишәрлектә автомобиль юлы төзелешенең беренче чираты» линия объекты территориясен ызанлау проекты Казан шәһәренең Совет районы территориясендә эшләнде.

Территорияне ызанлау проекты линия объектын план буенча урнаштыру чикләрендә территорияне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, гомуми файдаланудагы җир кишәрлеген формалаштыру, гамәлдәге капиталь төзелеш объектларын исәпкә алып, кызыл линияләр билгеләү максатыннан әзерләнде.

2020 елның 31 июлендәге 254-ФЗ номерлы «Магистраль инфраструктураны модернизацияләү һәм киңәйтү максатыннан аерым мөнәсәбәтләрне җайга салу үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы федераль законның 3 статьясындагы 2 пункты нигезендә инфраструктура объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре мондый инфраструктура объектлары территориясен планлаштыру буенча расланган документлар белән билгеләнә.

Линия объектын план буенча урнаштыру чикләрендә гомуми файдаланудагы җир кишәрлеген төзү максатыннан 2 этапта кадастр эшләре башкару таләп ителә:

1 нче этапта ясала торган җир кишәрлекләре турындагы белешмәләр, шул исәптән башлангыч һәм ясала торган җир кишәрлекләренең мәйданы, рөхсәт ителгән файдалану төре турындагы белешмәләр, ясау ысуллары һәм дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен мәҗбүри алу турындагы белешмәләр 3, 4 нче таблицаларда бирелгән.

3 нче таблица

## Ясала торган җир кишәрлекләре исемлеге (ЗУ). 1 этап

| **Беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры** | **Беренчел җир кишәрлегенең милек формасы** | **Беренчел җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре** | **Ясала торган җир кишәрлегенең билгеләнеше** | **Мәйдан, кв.м** | **Билгеләнә торган рөхсәт ителгән файдалану төре** | **Ясалу ысулы** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 16:50:140205:6 | Аерым билгеләр: хосусый милек | Шәхси йорт | 16:50:140205:6:ЗУ1 | **62** | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Беренчел кишәрлек сакланган хәлдә үзгәртелгән чикләрдәге бүленеш |
| 16:50:140208:6 | Аерым билгеләр: хосусый милек | Шәхси йорт | 16:50:140208:6:ЗУ1 | **261** | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Беренчел кишәрлек сакланган хәлдә үзгәртелгән чикләрдәге бүленеш |
| - | - | - | 16:50:000000:ЗУ1 | **1103** | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән ясау |

4 нче таблица

## Ясала торган җир кишәрлекләре исемлеге. 2 этап

| **Беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры** | **Беренчел җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре** | **Ясала торган җир кишәрлегенең билгеләнеше** | **Мәйдан, кв.м** | **Билгеләнә торган рөхсәт ителгән файдалану төре** | **Ясалу ысулы** |
|---|---|---|---|---|---|
| 16:50:140205:6:ЗУ1<br>16:50:140208:6:ЗУ1<br>16:50:000000:ЗУ1<br>16:50:140208:84<br>16:50:140208:33 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | 16:50:000000:ЗУ2 | **10521** | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне яңадан бүлү |

Кадастр эшләренең 1 этабында ясала торган җир кишәрлекләре өчен беренчел булган җир кишәрлекләренә кадастр эшләренең 2 этабын үткәрү алдыннан Казан шәһәренең муниципаль милек хокукын теркәргә.

2 нче этапта ясала торган җир кишәрлекләре өчен беренчел булып торган җир кишәрлекләре чиктәш булып тора.

Ызанлау проектының 2 этабын гамәлгә ашыру 1 нче этапта җир кишәрлекләре ясау буенча кадастр эшләрен башкарганнан соң гына мөмкин.

2 этапта ясала торган җир кишәрлекләре чикләрендә юл сервисы объектлары булып тормый торган капиталь төзелеш объектлары юк.

Гомуми файдаланудагы территорияләргә яки гомуми файдаланудагы милеккә кертеләчәк ясала торган җир кишәрлекләренең мәйданы, инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитутлар мәйданы турындагы белешмәләр һәм исемлек 5, 6, 7, 8 таблицаларда китерелгән.

5 нче таблица

**Гомуми файдаланудагы территорияләргә яисә гомуми файдаланудагы милеккә кертеләчәк ясала торган җир кишәрлекләренең мәйданы турындагы исемлек һәм белешмәләр. 1 нче этап**

| **Шартлы билге** | **Җир кишәрлегенең мәйданы, кв.м** | **Ясала торган җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төре** | **Мәҗбүри алу** |
|---|---|---|---|
| 16:50:140205:6:ЗУ1 | **62** | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Өлешчә |
| 16:50:140208:6:ЗУ1 | **261** | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Өлешчә |

6 нчы таблица

**Гомуми файдаланудагы территорияләргә кертеләчәк шәхси милектәге җир кишәрлекләренең мәйданы турында белешмәләр һәм аларның исемлеге. 1 этап**

| **Шартлы билге** | **Җир кишәрлегенең мәйданы, кв.м** | **Ясала торган җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төре** | **Мәҗбүри алу** |
|---|---|---|---|
| 16:50:140208:84 | **673** | Шәхси йорт | Тулысынча |
| 16:50:140208:33 | **835** | Шәхси торак төзелеше | Тулысынча |

7 нче таблица

**Гомуми файдаланудагы территорияләргә яисә гомуми файдаланудагы милеккә кертеләчәк ясала торган җир кишәрлекләренең мәйданы турындагы исемлек һәм белешмәләр. 2 нче этап**

| **Шартлы билге** | **Җир кишәрлегенең мәйданы, кв.м** | **Рөхсәт ителгән файдалану төре** |
|---|---|---|
| 16:50:000000:ЗУ2 | **10521** | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) |

8 нче таблица

**Инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитутларының мәйданы турында исемлек һәм белешмәләр**

| **Җир кишәрлегенең кадастр номеры** | **Ачык сервитут мәйданы** | **Рөхсәт ителгән файдалану төрләре** |
|---|---|---|
| 16:50:140355:15 | **52** | Нокса елгасы |
| 16:50:140205:6 | **62** | Шәхси йорт |
| 16:50:140208:7 | **2** | Шәхси торак йорт һәм аның янәшәсендәге территория |